БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_07_» _05_ 2019 г. № _183__

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын муниципаль учреждение хезмәткәрләренә эш командировкалары белән бәйле рәвештә командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясы нигезендә, бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалану, җирле бюджеттан финанслана торган командировка чыгымнарына бәйле Муниципаль учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына билгеләнгән тәртиптә чыгымнарны финанслауны расланган Нигезләмә нигезендә тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге әлеге карарны муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерергә тиеш.

4. Муниципаль учреждение җитәкчеләренә үз хезмәткәрләрен расланган Нигезләмә белән таныштырырга.

5. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең командировка чыгымнарын кайтарганда әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәгә һәм гамәлдәге законнарга таянып эш итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов